Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Татарско-Шуганского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. Советская, д. 41в, село Татарский Шуган,
Азнакаевский район, 423327

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Татар Шуганы авылы
җирлеге башкарма комитеты

Совет урамы, 41в нче йорт, Татар Шуган
авылы, Азнакай районы, 423327

Тел. (факс) 8(85592) 36-1-41; e-mail: Tshug.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» ноябрь 2018 ел № 35

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Татар-Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары нигезендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Татар-Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын әзерләргә (29.11.2016 №46, 04.09.2017 №65, 03.07.2018 №104 карарлар редакциясендә):

1.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелгән үзгәрешләргә туры китерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Татар-Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык ______________________ Г.З.Мияссарова